**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ НОВОИЛЬМОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Улица Ключевая, дом 15, село Новое Ильмово, Черемшанский район, РТ, 423118

**ТАТАРСТАН**
**РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ЯҢА ЭЛМӘЛЕ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Чишмә урамы, 15 нче йорт, Яңа Элмәле авылы, Чирмешән районы, РТ, 423118

Телефон: (84396) 2-45-51, факс: (84396) 2-45-51 email: Nilm.Cmn2@tatar.ru

**№12** **15.12.2025 ел**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**Яңа Элмәле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**Яңа Элмәле авыл җирлеге**
**Башкарма комитетының**
**2026 елга җирле әһәмияттәге**
**мәсьәләләрне хәл итүгә бюджет**
**ассигнованиеләре бүлеп бирү**
**турындагы мөрәҗәгатен карау хакында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 24.5 статьясына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 77 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 октябрендәге 288-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Яңа Элмәле авыл җирлеге Уставы нигезендә, Яңа Элмәле авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы 2025 елның 10 декабрендәге 120 номерлы мөрәҗәгатен карап, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2026 елга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Яңа Элмәле авыл җирлеге бюджетына бюджет ассигнованиеләренең җитәрлек булмавын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Яңа Элмәле авыл җирлеге башкарма комитеты мөрәҗәгатендә күрсәтелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә аерым вәкаләтләрне финанслаудан кушымта нигезендә баш тартырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Яңа Элмәле авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе: И.М.Җамалтдинов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Яңа Элмәле авыл җирлеге
Советының 2025 елның
15 декабрендәге
12 номерлы карарына
1 нче кушымта

**2026 елда бюджет ассигнованиеләрен бүлеп бирү өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләр исемлеге**

| № п\п | Бюджет ассигнованиеләре белән ныгыту өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрнең аталышы | БАРЛЫГЫ, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Су белән тәэмин итүгә лицензия алу өчен документлар әзерләү | 2 000 000 |
| 2 | Янгын гидрантларын ремонтлау һәм алыштыру | 200 000 |
| 3 | Дератизация чараларын үткәрүне тәэмин итү | 100 000 |
| 4 | Эшчәнлек төренә санитар-эпидемиологик нәтиҗә алу | 200 000 |
| 5 | Җирле әһәмияттәге юлларны норматив хәлдә тоту өчен махсус реагентлар сатып алу | 100 000 |
| 6 | Рөхсәтсез чүплекләрне рекультивацияләү | 700 000 |
| 7 | Янгын сүндергечләр сатып алу, тутыру | 4 800 |
| 8 | Металлодетекторлар сатып алу | 17 000 |
| 9 | Тавыш белән ашыгыч хәбәр итүнең автоном системасын урнаштыру | 20 000 |
| 10 | Видеокүзәтү системасын урнаштыру, ремонтлау | 100 000 |
| 11 | Гидротехник корылманы декларация алды тикшерүе | 4 000 000 |
| 12 | Гидротехник корылмаларны карап тоту | 3 000 000 |
| | **БАРЛЫГЫ** | 10 441 800 |